УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**Казан ш.**

**«29» апрель, 2019 ел.** **№ 31**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең 2017 елның 20 июлендәге 41 номерлы боерыгы белән расланган Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы федераль закон белән «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пунктына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең «Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына

керүгә рөхсәт бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 июлендәге 41 номерлы боерыгы белән расланган Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциясез оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең 1 пунктындагы икенче абзацта «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы» сүзләрен төшереп калдырырга;

Тәртипкә 1 нче кушымтада «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы» сүзләрен төшереп калдырырга.

**Идарә башлыгы** **Г.Р.Нигъмәтуллина**